| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**11.04.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 79** |

Татарстан Республикасының “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законнар нигезендә. Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының
2016 елның 11 апрелендәге
79 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәрләр коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрергә бурычлы.

Хәбәр вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамә рәвешендә язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба - хәбәрнамә).

3. Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә төзелгән форма буенча хәбәрнамәне җибәрә.

4. Яллаучы вәкиленә кергән хәбәрнамәләр карау өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында барлыкка килә торган мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәлеше буенча тиешле комиссияләргә (алга таба – Комиссия, Комиссияләр) тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләр, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.

5. Хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән нәтиҗә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Комиссия утырышына тапшырыла, ул Комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде эш көне эчендә уздырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар яллаучы вәкиленә хәбәр килгән көннән алып 45 көн эчендә Комиссиягә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.

6. Комиссия, Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган Комиссия турында Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны яллаучы вәкиленә җибәрә.

7. Яллаучы вәкиле тарафыннан Комиссия карау нәтиҗәләре буенча хәбәрнамәләр комиссиясе тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгы булмавын таныырга;

б) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан шәхси кызыксынучанлык мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерә ала торган дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген танырга.

8. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә яллаучы вәкиле мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрүне тәэмин итә яисә хәбәрнамә җибәргән затка мондый чаралар күрергә киңәш итә.

9. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, яллаучы вәкиле Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын куллана.

Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү хакындагы Нигезләмәгә кушымта

____________________________
(танышу турында тамга)

______________________________________
(яллаучы вәкиленә)

______________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа)

## вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ХӘБӘРНАМӘ

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр: ____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар:________________________________________________
____________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар ________________________________________________
____________________________________________________________________

Әлеге хәбәрнамәләрне караганда (кирәклесен ассызыкларга) Татарстан Республикасы ___________________________муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләре үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Комиссия утырышында шәхси катнашырга ниятлим (ниятләмим)

«___»________________ 20__ ел ____________________ ___________________________
(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаны расшифровкалау)